ВАКЫЙГА
2024 елга мөселман бәйрәмнәре календаре расланды
→ 3 БИТ

ВӘГАЗЬ
Тапланган йөрәк ни белән куркыныч?
→ 4–5 БИТ

СОРАУ-ҖАВАП
Азанның асылы нәрсәдә?
→ 10–11 БИТ

НӘСЫЙХӘТ
Аллаһы Тәгаләнең Әл-Бари исеме нәрсәне аңлата?
→ 12 БИТ

**ОКТЯБРЬ, 2023**
№ 10 (339)

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте басмасы

РАБИГЫЛЬ-ӘҮВӘЛ–РАБИГЫЛЬ-АХЫР, 1445

# دين و معيشت

# ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

12+



Фотоның авторы: ayman-zaid / elements.envato.com

**Кәгъбәтуллаһ – мөселманнарның төп изге урыны һәм Ислам дөньясында аның әһәмияте чиксез зур. Мәккәдә Кәгъбәтуллаһ тирәли 7 тапкыр тәваф кылына. Аның һәр почмагының үз әһәмияте һәм фазыйләте бар...**

ДӘВАМЫ → 8–9нчы БИТТӘ

ГАЗЕТАДА АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘНЕҢ ИСЕМНӘРЕ, КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ БУЛГАНЛЫКТАН, БАСМАГА ИГЪТИБАРЛЫ БУЛЫГЫЗ!

## ТАТАРСТАН МӨФТИЕ БЕЛӘН КФУ РЕКТОРЫ ЛЕНАР САФИН ОЧРАШТЫ


Фото КФУ матбугат хезмәтеннән алынды

**13 нче октябрь көнне Татарстан Мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин белән Казан федераль университеты ректоры Ленар Сафин очрашты. Очрашуда шулай ук мөфтинең мәгълүмати сәясәт буенча урынбасары, «Хозур» нәшрият йорты генераль директоры Ришат Хәмидуллин, КФУның Халыкара мөнәсәбәтләр институты директоры Рамил Хәйретдинов һәм Н.И. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханә директоры урынбасары Эльмира Амерханова катнашты.**

Очрашуда татар дин галимнәренең хезмәтләрен популярлаштыру, саклау һәм тарату өлкәсендәге хезмәттәшлекнең беренче нәтиҗәләре турында фикер алыштылар.

Университет һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәте әлеге юнәлештә күптәннән тыгыз хезмәттәшлек итә. Хезмәттәшлек турында килешү имзаланганнан соң 5 ел эчендә КФУ галимнәре һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәте структурасындагы республика дини белем бирү учреждениеләре вәкилләре, «Хозур» нәшрият йорты мәшһүр татар дин галимнәре һәм мәгърифәтчеләре хезмәтләрен ачыклау, цифрлаштыру һәм бастырып чыгару, күргәзмәләр оештыру һәм мәгърифәтчелек белән бәйле проектларны тормышка ашыру буенча зур эш башкарды.

Мәсәлән, уртак башлангыч белән Казан университетының эчке ишегалдындагы диварында мөселман дөньясында беренче басма Коръән («Казан басмасы») басылу хөрмәтенә мемориаль такта ачылды, йөзләгән мөселман кулъязмалары һәм китаплары цифрлаштырылды, аларның кайберләре университет һәм ТР мөселманнары Диния нәзарәте сайтларында урнаштырылды.

Якын арада яңа килешү төзү көтелә: ул үз эченә күп кенә заманча юнәлешләрне һәм уртак эшчәнлек формаларын, шул исәптән тикшеренүчеләрнең UNIVER TV һәм «Хузур ТВ» каналы программаларында катнашуын, яңа телевизион проектлар булдыруны алачак.

Ленар Сафин шулай ук Мөфтине КФУ студентлары һәм укытучылары алдында ачык лекцияләр укырга чакырды.

Университет ректоры очрашу ахырында Камил хәзрәт Сәмигуллинга, күренекле татар мәгърифәтчесе, дин галиме һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Баруди коллекциясеннән кулъязмалар күчермәсен [«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе тарихы музее экспозициясенә урнаштыру өчен] тапшырды.

Кулъязмаларның күчермәләре бушлай бирелде. Алар арасында 1883 елда Г. Баруди тарафыннан оештырылган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә уку процессын алып бару турында материаллар, галимнең дин һәм җәмәгать эшлеклеләре белән алышкан хатлары, мәдрәсә шәкертләренең дәресләре һәм имтиханнары расписаниесе, лекцияләр конспектлары, көндәлекләре һәм шигырьләр җыентыклары бар.

**ДУМ РТ** сайтыннан

## «ИСЛАМ. БЕРЕНЧЕ АДЫМНАР» МӘКТӘБЕ ЯҢА СЕЗОНЫН АЧЫП ҖИБӘРДЕ

**14 нче октябрьдә Нәзарәттә «Ислам. Беренче адымнар» мәктәбенең 12нче сезоны ачылды. Беренче дәрес Нәзарәт бинасында узды: бу агымда 200дән артык кеше намаз укырга һәм Ислам нигезләренә төшенергә теләк белдерде. Аларның күпчелеге хатын-кызлар. Шәкертләр атнасына бер тапкыр уздырыла торган 7 дәресне үзләштерәчәк.**

Алар алдында ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең социаль үсеш бүлеге башлыгы Айгөл Биктимирова чыгыш ясады. Ул, Аллаһ юлында белем алуның фазыйләтләрен аңлатып, һәркемнең тормышында аны үзгәртүче вакыйгалар булуын билгеләп үтте һәм «Ислам. Беренче адымнар»ның шәкертләр тормышын тулысынча үзгәртүен теләде. Айгөл Биктимирова мөселманнарның Коръән кушканча яшәвен – Аллаһы Китабында һәм Мөхәммәд пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисләрендә белем алу юлындагы кешенең дәрәҗәсе зур булуын билгеләп үтте. Аның сүзләренчә, хәдисләрдә Аллаһының белем эстәгән кешегә җәннәткә юлны җиңеләйтүе; фәрештәләрнең инсаннарны саклап йөртүе һәм барлык тере җан ияләре – җир астындагы бөҗәкләрнең дә, су астындагы хайваннарның да бу кешеләр өчен Аллаһыдан гафу сораулары китерелә.

Лекцияләр хатын-кызлар һәм ир-атлар өчен аерым рәвештә, татар һәм рус телләрендә уза. Укулар һәр шимбә көнне Казанның Галиев һәм Зәңгәр мәчетләрендә, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә һәм мөфтияттә иртәнге сәгать сигездән төшке уникегә кадәр оештырыла.

Дәресләрдә тәһарәт һәм госел алырга, намаз укырга өйрәтәчәкләр, гакыйдә, Мөхәммәд пәйгамбәр саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормыш юлы, ураза һәм төрле гыйбадәтләр турында сөйләячәкләр.

«Ислам. Беренче адымнар» мәктәбе 5 ел буе мәчет каршындагы курсларга йөрергә мөмкинлекләре һәм вакытлары булмаган, әмма мөселман үтәргә тиешле гыйбадәтләрен башкарып яшәргә теләүче дин кардәшләр өчен оештырыла.

Проект Татарстан мөфтияте тарафыннан дәгъват эшчәнлеге кысаларында 2018 елда тормышка ашырыла башлады. Унбер сезон дәвамында әлеге курсларда 1078 кеше белем алды һәм намазга басты.

**ДУМ РТ** сайтыннан

# 2024 елда мөселман календарендә бәйрәмнәр һәм истәлекле көннәр

## Һиҗри исәп буенча 1445–1446 еллар

| | | |
|---|---|---|
| 12 гыйнвар | 1 Раҗәб | |
| 11нче гыйнвардан 12сенә каршы төн | 29нчы Җөмәдәл-ахырдан 1нче Раҗәбкә каршы төн | **Рагаиб кичәсе** |
| 6нчы февральдән 7сенә каршы төн | 26нчы Раҗәбтән 27сенә каршы төн | **Мигъраҗ** |
| 11 февраль | 1 Шәгъбан | |
| 24нче февральдән 25сенә каршы төн | 14нче Шагъбаннан 15енә каршы төн | **Бәраәт кичәсе** |
| 11 март | 1 Рамазан | **Рамазан ае башлана** |
| 5нче апрельдән 6сына каршы төн | 26нчы Рамазаннан 27сенә каршы төн | **Кадер кичәсе** |
| 10 апрель | 1 Шәүвәл | **Ураза гаете** |
| 9 май | 1 Зөлкагдә | |
| 7 июнь | 1 Зөлхиҗҗә | |
| 15 июнь | 9 Зөлхиҗҗә | **Гарәфә көне** |
| 16 июнь | 10 Зөлхиҗҗә | **Корбан гаете** |
| 15–19 июнь | 9, 10, 11, 12, 13 Зөлхиҗҗә | **Тәкъбир әт-Тәшрикъ көннәре** |
| 7 июль | 1 Мөхәррам | **Һиҗри буенча 1446 ел башлана** |
| 16 июль | 10 Мөхәррам | **Гашурә көне** |
| 5 август | 1 Сафәр | |
| 4 сентябрь | 1 Рабигыль-әүвәл | |
| 14нче сентябрьдән 15енә каршы төн | 11нче Рабигыль-әүвәлдән 12сенә каршы төн | **Мәүлидән-Нәби** |
| 4 октябрь | 1 Рабигыль-ахыр | |
| 3 ноябрь | 1 Җөмәдәл-әүвәл | |
| 2 декабрь | 1 Җөмәдәл-ахыр | |

## 2024 ЕЛГА МӨСЕЛМАН БӘЙРӘМНӘРЕ КАЛЕНДАРЕ РАСЛАНДЫ


Фотоның авторы: erika8213 / elements.envato.com

**ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы Һиҗри буенча 1445–1446 елларга яки Милади буенча 2024 елга мөселман бәйрәмнәре һәм истәлекле көннәр календарен раслады.**

Һиҗри календарь 12 айдан тора һәм Мөхәррам аеннан башлана. Мөселман календаре айларының башын һәм ахырын билгеләгәндә ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы җирле географик үзенчәлекләргә һәм астрономик мәгълүматларга таяна.

2024 елда изге Рамазан ае 11нче мартта башланачак. 2024 елның 10нчы апреле – Ураза бәйрәме. Тагын бер бөек мөселман бәйрәме булган Корбан гаете 16нчы июньдә билгеләп үтеләчәк.

**dumrt.ru** сайтыннан алынды

## ЯҢАРТЫЛГАН «КАЗАН БАСМАСЫ» ҮЗБӘКСТАНГА КИТТЕ

**5нче октябрь, Татарстан Республикасына эш сәфәре белән Үзбәкстан Республикасы Президенты Шәүкәт Мирзиёев килде. Эш сәфәре Россия Федерациясенә рәсми сәфәр кысаларында узды.**

Үзбәкстан Республикасы Президенты Шәүкәт Мирзиёев Татарстанда вакытта «Казан Кремле» музей-тыюлыгының тарихи объектларында булды. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов һәм башка рәсми затлар белән бергә Шәүкәт Мирзиёев Кол-Шәриф мәчетен карады һәм әлеге объектның барлыкка килү тарихы белән танышты. Мәчет янында кунакны Татарстан Мөфтие, ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Камил хәзрәт Сәмигуллин каршы алды. Ул кунакка Коръәннең яңартылган «Казан басмасы»н бүләк итте.


ТР Рәисенең матбугат хезмәте. Фотоның авторы: Илнур Мифтахов / dumrt.ru

**dumrt.ru** сайтыннан алынды

# ТАПЛАНГАН ЙӨРӘК НИ БЕЛӘН КУРКЫНЫЧ?

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең олуг бер нигъмәтләренең берсе – безгә яшәү нигъмәтен бирүендә.

Бу дөньяга килгән һәркемнең жаны һәм тәне бар. Һәркайсыбыз тәнебезне, халәтебезне «ишетәбез» һәм хәзерге вакытта ни кирәген аңлыйбыз. Әйтик, берәр җиребез авыртса, дәвалану ысулын карыйбыз; тамагыбыз ачса, ризыкланабыз; туңсак, җылынырга кирәклекне беләбез; эссе булса, суыну ысулларын эзлибез. Аллаһы Тәгалә биргән әманәтебезне – шушы тәнебезне саклыйбыз, кадерлибез, хөрмәтлибез. Югарыда саналганнарның барысы да – безнең бурычыбыз, динебезнең олуг бер кагыйдәседер. Тик мөэмин мөселман болар белән генә чикләнмичә, «җан» сәламәтлеген дә кайгыртырга тиеш. Аның үлчәмен, авырлыгын белмәсәк тә, җаныбызның барлыгын барчабыз да беләбез.

### ҖАН ЧИСТАЛЫГЫ...

Җаныбызны калеб дип әйтү дә дөрес булыр. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә безгә шул калебне биргән икән, без дә аны чиста һәм төзек хәлдә сакларга тиеш. Тәнебез, киемебез пычранган кебек, йөрәк тә пычрана. Тәннәребез турында кайгырткан кебек, җаннарыбыз, йөрәкләребезне дә кайгыртырга кирәк. Җаннарыбызның нинди хәлдә булуы бездән соралыр.

Аллаһы Раббыбыз җанны безгә төзек, матур, чиста хәлдә тапшырды. Адәм баласы дөньялыкка килгәндә, сабый бала нинди күркәм сурәттә булса, аның җаны да шундый ук матур һәм камил була. Әмма тиешле тәрбия җитмәсә, кеше Аллаһы Тәгаләне танымаса, җанга зыян салырга, аны пычратырга, авыруга сабыштырырга мөмкин. Кешегә шушы җаннарны юктан бар кылган, аларга нәрсә яхшы, нәрсә начар икәнен белгән Аллаһы Раббыбызның сүзен, Аның әйткәнен тыңлап, шушы тәнәребезне чиста һәм матур хәлдә саклау тиешле. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә Коръәни Кәримдә безгә моның турында ачыктан-ачык хәбәр итә:

*«[Хәерле юлда сарыф ителсә дә] **Бер малның да,** [шафәгать итә алырлык дәрәҗәдә булган] **улларның да** [беркемгә] **файда бирмәгән көнне. Мәгәр** [көферлек һәм монафикълык кебек хасталыклардан тәмам котылып] **керсез күңел белән Аллаһыга килүче булмаса гына».***

*«Әш-Шүгәра / Шагыйрьләр», 26:88-89*

*Шулай ук Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Әгәр адәм баласы гөнаһ кылса, йөрәгендә кара тап барлыкка килә, әгәр гөнаһын калдырып, тәүбә кылса, Аллаһы Тәгалә шушы тапны чистартыр. Ләкин адәм баласы шушы гөнаһны кабатлап, гөнаһлары күбәйгәннән-күбәя икән, аның калебен кара тап каплап алыр», – ди.*

Аллаһы Тәгалә әлеге аятьтә кешегә изге гамәлләреннән һәм чиста йөрәгеннән кала берни дә булышмаячагын әйтә. Бары тик чиста калеб кенә ярдәмгә килер. Аллаһы Тәгаләнең Хаклыгын хак итеп таныган, Аның сүзләреннән тайпылмаган, Аның барлыгын, берлеген белеп яшәгән калеб иң зур файда китерер. Шушы калебең ни дәрәҗәдә чиста, төзек, авырулардан пакь булса, шул дәрәҗәдә файда китерер. Йөрәкне чиста хәлдә саклап яшәү – ул мөселман кешесенең олуг бер бурычыдыр.

### ЙӨРӘКЛӘР НИК ТАПЛАНА?

*«**Юк!** [Бу бозык бәндәнең сүзе һич дөрес түгел!] **Кылган** [начар] **нәрсәләре** [һәм рәттән эшләгән гөнаһлары] **аларның йөрәкләрен** [мәгънәви бер] **тутык белән каплаган».***

*«Әл-Мутаффифин / Киметеп үлчәүчеләр», 83:14*

Беренчедән, адәм баласының көндәлек кылган гамәлләре аңа авырлык китерергә, аның йөрәгендә кара таплар калдырырга һәм аны авыруга дучар итәргә мөмкин икән.

Икенчедән, шул аңлашыла: кеше гөнаһ кылган саен, шул пычрак арта һәм, йөрәкне дә пычрак хәлдә калдырсак, ул пычрак юа алмаслык дәрәҗәгә җитәргә мөмкин. Шуңа күрә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтә: «Әгәр дә кеше гөнаһта дәвамлы икән, гөнаһтан кире кайтмыйча, тәүбәгә килмичә, наданлыкта, имансызлыкта, Аллаһы Тәгаләне танымыйча яшәсә, аның шушы тап арткаnнан-артып, калебе капланыр».

Өченчедән, шуны аңларга кирәк: кылган гөнаһыңны калдырып, тәүбә-истигъфарда булсаң, Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә калебеңне чистарта икән. Тагын бер хәдисендә пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Әгәр дә адәм баласы гөнаһ кылганнан соң тәүбә итсә, ул гөнаһ кылмаган дәрәҗәдә булыр». Ягъни Аллаһы Тәгалә каршында аңлап, чын күңелдән тәүбәгә килеп, Аллаһы Тәгалә кабул итсә, аның калебе яңадан чистарыр икән.

Дүртенчедән, шушы хәдистән аңларга тиешле әйбер – ул калебнең катылануы, аның каплануы: адәм баласының калебе яхшылыкны ишетми, күрми, аңламый башлый. Безнең халкыбызда «Бу бәндәнең йөрәге катты» дигән сүз бар. Димәк, ул кеше яхшы сүзне ишетми, изге гамәлләрне күр-


Фотоның авторы: IrynaKhabliuk / elements.envato.com

ми башлый. Бу – иң куркынычыдыр. Аллаһы Тәгалә безне шушы халәттән сакласа иде.

### ҖАННАРНЫ НӘРСӘ ЧИСТАРТА?

Безне юктан бар кылган Аллаһы Раббыбыз әйткән әйберләр, Аның кушканнары, Аның әйткән сүзләре безнең калебләребезгә шифа, дәва һәм чисталык бирәдер. Раббыбыз кушканнарны үтәп яшәү йөрәкләребезне төзек һәм дөрес хәлдә тотуга ярдәм итә икән.

Иң беренче эш итеп, тәүбә-истигъфар, зикердә Аллаһы Тәгаләне олуглау, шөкер итү кирәк була. Адәм баласы белеп яки белмичә, кайдадыр аңлап җиткермичә, онытылып, ялкауланып китеп ялгышырга мөмкин. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткәнчә: «Адәм баласы хаталанучан, ә иң хәерлегез, хатасын аңлап, тәүбәгә килеп, кичерү сораучыгыз». Шуңа күрә без, иң беренче, Аллаһы Раббыбыз каршында ялгыш, хаталы гамәлләребез өчен гафу сорап, калебләребезне чистарту кирәк буладыр.

Калебләребезне саф хәлгә китергәннән соң, безгә шушы чиста «савытларыбызны» саф, чиста әйбер белән генә тутырырга (изге гамәлләр кылырга) кирәк. Гамәл дигәндә, шушы Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын үтәү, намазларны торгызу, ураза тоту, хәерле гамәл кылуда дәвамлы булу күзаллана. Аллаһы Тәгалә каршында чиста күңел, чиста калеб белән булыр өчен тәүбә-истигъфарда булыйк. Иртән торганда, кич ятканда шушы тәүбәләребезне кылып яшик. Пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Мин көненә җитмеш мең истигъфар кылам, Аллаһыдан кичерү сорыйм», – диде. Без дә, хаталанган, ялгышкан булсак, Аллаһы Тәгаләдән кичерү, ярлыкау сорыйк.

Кемдер: «Мин моны соңрак, пенсиягә чыккач эшли алам, соңрак тәүбәгә килермен», – дип үзен тынычландырып йөрергә мөмкин. Ләкин беркем дә ахыргы сулышы кайчан икәнен белми. Бүгенге калебең белән Аллаһы Тәгалә хозурына күчсәң, нәрсә дип җавап бирерсең? Моның турында да уйлану кирәктер. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер хәдисендә: «Кеше ничек яшәгән, шул рәвешле Аллаһы Тәгаләгә күчә», – ди.

### КИҢӘШ...


Көн тудымы, кич җиттеме – Аллаһыны зикер итик. Шушы рәвешле калебләребезне чиста хәлдә тота алсак, без сөенербез. «Аллаһыга шөкер, мин – мөселман, Син миңа биргән калебне зикер-тәсбих белән тутырдым, аны чистарттым, төзек хәлдә Сиңа тапшырам», – дип Аллаһы каршына килсәк, хәерлесе шул булмасмы? Тәннәребезне саклаган кебек, калебләребезне дә сакласак иде. Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгалә үзенең каршына Ул разый була торган хәлдә килеп бассак иде. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм кебек Аллаһыга дога кылыйк: «Йә Раббым, Үзеңнең динеңдә мине ныгыт». Аллаһы Раббыбыз һәрбарчабыздан да разый булсын!

**Инсаф хәзрәт Ибатуллин,**
Казан шәһәренең «Динислам» мәчете имам-хатыйбы

ДИН вә МӘГЫЙШӘТ
№ 10 (339) октябрь, 2023 | Рабигыль-әүвәл– Рабигыль-ахыр, 1445

# ХАҖ-2024: әзерлек башланды

**Хаҗ кылу – күпләрнең хыялы. Әмма хыялны чынга ашыру өчен, теләк кенә җитми, Аллаһы Тәгаләнең безне үзенә кунакка чакыруы кирәк. Аллаһтан – чакыру, бездән ихлас ният һәм Хаҗ сәфәренә барырга тырышу кирәк. 2024 елда хаҗ сәфәренә нинди таләпләр бар, аңа ничек әзерләнергә кирәклеген белер өчен, Диния нәзарәтенең рәсми Хаҗ операторы генераль директорының урынбасары Азат Хөрмәтуллин белән әңгәмә кордык.**


Фотоның авторы Илназ Мөхерләмов

***– Азат әфәнде, әссәламү галәйкүм. Хаҗның гомуми таләпләре хакында сөйләп китсәгез иде.***

– Вәгаләйкум әссәлам вә рәхмәтуллаһ. Хаҗ кылу – ислам дине баганаларының берсе. Шул сәбәпле ул сау-сәламәт, балигъ, үз акылында һәм ирекле, юл чыгымнарын күтәрергә матди мөмкинлеге булган, үзе хаҗда вакытта, гаиләсенә яшәү чыгымнарын капларлык барлык башка мөһим мохтаҗлыклардан азат очракта, һәр мөселманның бурычы (фарыз гамәл). Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ике кече хаҗ кылу арасында кеше барлык гөнаһларыннан котыла, ә зур хаҗ өчен бүләк булып оҗмах тора», – диген. Хаҗ гамәлен үз гомерендә бер тапкыр булса да үтәү зарур. Бәлки якын арада безгә дә, сезгә дә шушы бурычыбызны үтәү мөмкинлеге бирелер, иншәАллаһ.

2024 елда булачак Хаҗ сәфәренә әзерлек инде башланган. Татарстан Диния нәзарәтенең рәсми хаҗ операторы киләсе елның 1нче февраленә кадәр Хаҗ сәфәренә барырга теләүчеләрдән гаризалар кабул итә.

*Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ике кече хаҗ кылу арасында кеше барлык гөнаһларыннан котыла, ә зур хаҗ өчен бүләк булып оҗмах тора», – диген.*

***– 2024 елда хаҗиларны нинди яңалыклар көтә?***

– Быел Хаҗ сәфәренә әзерлек сроклары бик кыска. Шуңа күрә, төрле авырлыклар белән очрашмас өчен, 2024 елның 1нче февраленә кадәр булачак хаҗилар сәфәргә бару ниятләрен төгәл билгеләргә тиешләр. Моннан тыш Хаҗ кылырга теләүчеләрдән чит ил паспортының яңа төре (10 еллык) булуы таләп ителә.

***– Виза мәсьәләсен ничек хәл итәргә?***

– Документларны, шул исәптән, виза әзерләүне без үз җилкәбезгә алабыз. Шуңа күрә ничек барам, кайда торам, нәрсә ашыйм, нинди документлар алып барыйм кебек сораулар белән борчылырга кирәкми. Хаҗиларны сәфәргә әзерләүдән башлап, озатып җибәрү, Изге җирләрдә каршы алу, гыйбадәтләрне кылырга ярдәм итү, дәресләр уздыру, ашарга алып йөрү, транспорт белән тәэмин итү мәсьәләләрнең барысын да рәсми хаҗ операторы хәл итә.

Моннан тыш «ДУМ РТ Хаҗ» рәсми хаҗ операторы махсус әзерлекле югары квалификацияле зур табиблар төркемен алып бара. Табиблар хаҗиларның тәүлек буена сәламәтлекләрен карап, кайгыртып торачак, кирәк вакытта ашыгыч ярдәм күрсәтәчәк. Сезнең сәламәтлек – ышанычлы кулларда.

***– Хаҗилар мондый олы сәфәрдә югалып калмасламы соң?***

– Юк, андый куркыныч янамый: һәр төркемнең үз җитәкчесе булачак. Җитәкче буларак баручыларның барысы да тирән гыйлемле, гарәп, рус һәм татар телләрен камил белгән зур тәҗрибәле хәзрәтләр. Барысы да берничә ел рәттән олы хаҗ кылып, ел дәвамында күп тапкырлар гомрә хаҗы кылган, хаҗиларга төрле авырлыкларны җиңәргә ярдәм иткән.

***– Балалар белән Хаҗ кылу дөрес буламы?***

Әйе, бала белән Хаҗ сәфәренә барырга ярый. Тик бала белән сәфәргә чыкканчы, кат-кат уйларга кирәк. Чөнки Хаҗ кылу бик әйбәт әзерлекле кеше өчен дә зур сынау. Кечкенә бала бу сынауны уза алырмы, аңа читен булмасмы? Шул хакта яхшылап уйлап, карар кабул итәргә кирәк. Әгәр баланы калдырып тору мөмкинлеге булса, мондый озын сәфәргә бала белән бармау хәерлерәк булыр.

***– Икенче елга яшь чикләүләре бармы?***

– Юк, 2024 елга бернинди яшь чикләүләре дә кертелмәде. Иң мөһиме хаҗиларның әзерлекле һәм сәламәт булуы кирәк.

***– Бурычлары булган кеше хаҗ кыла аламы?***

– Бурычларны түләп бетермичә хаҗга бару дөрес түгел.

Әмма кайбер кешеләр, бурычлары була торып та, хаҗ кыла, һәм, шул рәвешле, үзенә зур зыян китерә. Чөнки бурыч кайтаруны юри сузып йөрү (яки бөтенләй кайтармау) гөнаһ булып тора. Бер хәдистә: «Сездән иң яхшысы булып бурычларын тизрәк түләп бетерүче тора», – диелгән. Түләнмәгән бурычлар өчен җаваплылык шулкадәр зур ки, бурычлы кеше үзенә тәмле, кыйммәтле ризыклар да алырга тиеш түгел. Башка чыгымнар турында сүз дә юк.

Әңгәмәне **Айгөл Абдрахманова** әзерләде

# АХМАК. ЯЛКАУ. МОНАФЫЙК. КЕМ КАЙСЫ БАСКЫЧТА?!

Бүгенге көн тизлеге һәм таләпләре безне көн саен төрле кешеләр белән күрешеп, танышып, аралашып торырга мәҗбүр итә. Еш кына кемнең кем булуын аңлау, истә калдыру бик читен була. Кайбер көннәрдә әйләнә-тирәдәге кешеләрне генә түгел, үзеңне танып-белеп булмый башлый. Шул нисбәттән, әлеге язма туды.

Хәзрәти Гали радыйаллаһү ганһү болай дип тапшырып калдырган: «Көннәрдән бер көнне Аллаһының Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм мине үз янына чакырды һәм болай диде: ***«Гали! Синең миңа якынлыгың Һарун пәйгамбәрнең Муса галәйһиссаләмгә якынлыгы кебек, ләкин миннән соң башка пәйгамбәр килмәячәк. Мин сиңа васыятьләремне калдырырмын. Тыңлаучан булсаң, шөкер итүчеләрдән булырсың һәм шаһитләр исәбеннән булырсың, Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә сине галим, гыйлем иясе итәр»***.

Шуннан Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дип дәвам иткән: «Гали, **мөэмин мөселманны** башкалардан аерып тора торган өч сыйфат бар:

1. Намаз уку.
2. Ураза тоту.
3. Садака бирү.

**Монафыйкларның** да төп өч билгесе бар:

1. Намаз укыганда янәшәсендә кеше булса, һәр рөкугъ, сәҗдәне җиренә җиткереп башкара. Ә үзе генә булганда намазга игътибарсыз һәм салкын карый.
2. Кеше мактаганда, эшләрен ихластан куанып, шатланып эшли.
3. Кеше янында булганда гына Аллаһы Тәгаләне искә ала, ә үзе генә калганда Аны оныта.

Болардан тыш, монафыйкларны билгели торган тагын берничә сыйфат бар:

1. Алар әйткән сүзләр – ялган.
2. Әйткән сүзләрендә тормыйлар.
3. Әманәт итеп бирелгән нәрсәләрне кире кайтармыйлар.

Гали! **Залим**нәрне дә башкалардан аера торган өч сыйфат бар:

1. Залим үзеннән түбәнрәк дәрәҗәдә булучыларны газаплый.
2. Мөмкинлек булса, башкаларның мал-мөлкәтен көч белән талап ала..
3. Ул үзенең өстендәге киеме, ашар ризыгы хәләл булуны кайгыртмый.

**Көнче**ләргә дә өч сыйфат хас:

1. Халык алдында булганда, кешегә ялагайлана.
2. Ә артыннан аның гайбәтен сөйли.
3. Башкаларның бәхетсезлегенә куана.

Гали, шуны бел! **Ялкау**ларның өч төп сыйфаты бар:

1. Ялкау Аллаһы Тәгалә алдындагы бурычларын үтәүдә ялкаулана.
2. Гыйбәдәтләрен иренеп кенә, сыйфатсыз итеп үти, шуңа күрә һәр кылган гамәле юкка чыга.
3. Ялкау кеше намаз укуны кичектерә һәм вакытында укымый.

**Тәүбә кылган** кешеләргә дә өч сыйфат хас:

1. Ул харамнан һәм шикле булган һәр нәрсәдән тыела.
2. Тәүбә кылган кеше дини гыйлем алырга тырыша.
3. Ана күкрәгеннән бер чыккан сөт кире керә алмаган кебек, тәүбә кылган кеше шул гөнаһка кире кайтмый.

**Акыллы** кешене дә өч сыйфат аерып тора:

1. Ул дөньяви мәшәкатьләргә игътибар бирми.
2. Акыллы кеше һәрчак авырлыклар кичерә.
3. Авыр вакытларда ул сабыр булып кала бирә.

**Сабыр** кешене дә өч төрле билге буенча танып була:

1. Ул туганлык җепләрен ныгыта һәм аның белән аралашмаучылар белән аралаша.
2. Ул үзен кысырыклаучыларга ярдәм кулы суза.
3. Сабыр холыклы кеше үзен җәберләүчеләр белән көрәшми.

**Ахмак** кешеләрнең дә өч сыйфаты бар:

1. Ул Аллаһы Тәгалә кушканнарны һәм фарыз гамәлләрне үтәүдә ялкаулауна.
2. Еш кына буш сүз сөйли.
3. Аллаһы Тәгалә бар кылган затларны кыерсыта һәм кимсетә.

Гали! **Бәхетле** кешеләрне дә өч билге буенча танып була:

1. Ул хәләл ризык белән генә тукләна.
2. Үз шәһәрендәге гыйлем бирү белән бәйле җыелышларга йөри.
3. Биш вакыт намазны җәмәгать белән укый.

**Бәхетсез** кешененең дә өч сыйфаты бар:


1. Харам ризык ашый.
2. Дини гыйлемнәрдән ерак тора.
3. Намазны үзе генә укуны кулай күрә».

Башкаларны алдарга тырышсак та, үзебезне алдый алмыйбыз. Караңгы урманга чыгып качсак та, уйларыбыз үзебез белән. Үзебезне алдарга тырышсак та, Аллаһыны алдап булмый. Ул – күрүче. Ул – белүче.

Һәрбарчабызга да сыйфат-билгеләребезне күркәм итеп, яманнар исәбеннән чыгып, ихлас күңелле, чиста калебле мөэмин мөселман булып яшәргә язсын иде.

**«Предания о четырех халифах»**
китабыннан

# Кәгъбәтуллаһның мөбарәк өлешләре




Рәсем авторы: Mbenoist (M. Benoist) / fr.wikipedia

1.Кара таш (Хәҗәр Әсвәд). 2. Кәгъбә ишеге. 3. Улак. 4. Шәзарван. 5. Исмәгыйль хиҗрәсе. 6. Мултәзәм. 7. Ибраһим мәкаме. 8. Кара таш почмагы. 9. Йәмән почмагы. 10. Шам почмагы. 11. Гыйрак почмагы. 12. Кәгъбә япмасы. 13. Ибраһим галәйһиссәлам басып торган җир.

**Кәгъбәтуллаһ – мөселманнарның төп изге урыны һәм Ислам дөньясында аның әһәмияте чиксез зур. Мәккәдә Кәгъбәтуллаһ тирәли 7 тапкыр тәваф кылына. Аның һәр почмагының үз әһәмияте һәм фазыйләте бар...**

## 1. КАРА ТАШ (ХӘҖӘР ӘСВӘД)

Кара таш Кәгъбәтуллаһның көнчыгыш ягына караган почмагында, җирдән 1,5 м биеклектә урнашкан. Ул көмеш кысага урнаштырылган кара-кызыл төстәге берничә кисәктән тора. Кара ташның көмеш каймасы беренче тапкыр Габдулла бине Зөбәер тарафыннан куела һәм алга таба зарурлык булган саен яңартыла.

Расүлүллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Кара таш җәннәттән килгән һәм сөттән ак булган. Кешеләрнең гөнаһларыннан ул каралган», – дигән (Тирмизи).

## 2. КӘГЪБӘТУЛЛАҺ ИШЕГЕ

Ибраһим галәйһиссәлам заманында Кәгъбәнең ике ишеге булган, кешеләр бер капкадан кереп, икенчесеннән чыкканнар. Керү юлы җир белән тигез булган. Корәешлеләр ишекне җирдән биек итеп ясагач, Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ишек биеклеген җир белән тигезләр идем, көнбатыштан һәм көнчыгыштан ике капка билгеләр идем», – дип әйткән булган (әл-Бохари).

Шуңа да карамастан, бүгенге көндә дә корәешлеләр үзгәртеп корганча Кәгъбәнең көнчыгыш ишеге генә калдырылган һәм бу ишек җирдән 2,5 м биеклектә урнашкан. Ишекнең төп өлеше агачтан ясалган һәм саф алтын пластинкалар (280 кг) белән бизәлгән. Соңгы тапкыр Кәгъбә ишеге 1397 һиҗри елда (1977–79 еллар) яңартылган. Мөбарәк Кәгъбә капкаларына мәрхәмәт, кисәтү һәм ярдәмне белдерүче Коръән аятьләре чокып язылган.


Элекке вакытларда Кәгъбә ишеге атнага ике тапкыр ачылган. Теләгән кеше аның эченә кереп намаз укый алган. Хәзер, хаҗилар саны күбәю сәбәпле, аның ишеге елга 2 тапкыр гына ачыла. Башка вакытта Изге йорт ишеге бикле тора. Ачкычы Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм рөхсәте белән Бәну Шәйбә нәселе кешеләрендә саклана, һәм бу Кыяматкәчә шулай калачак. Гади кеше булсынмы, солтан булсынмы, Кәгъбәтуллаһка керү өчен рөхсәт, иң беренче, әлеге гаилә башлыкларыннан алына.

Кәгъбә ишегенең борынгы ачкычы бик нык күгәргән була. Госманлылар

**ТР МДНнең «Хозур» нәшрият йорты Мөхәммәд Йәлкәнҗинең «Сунна. Нет религии без Посланника Аллаха саллаллаху ‘алейхи ва саллям» («Сөннәт һәм аның Ислам динендәге әһәмияте») китабын нәшер итте**

Сөннәткә мөрәҗәгать итмичә, Коръәни Кәрим белән генә чикләнеп калу — ул гыйбадәтнең иң төп: намаз, зәкят, ураза, хаҗ кебек рөкеннәрен белмәүгә китерә. Коръәни Кәрим безгә ачыктан-ачык әлеге гамәлләр фарыз икәнен күрсәтә, ләкин аларны үтәү тәртибен өйрәтми.

Коръәни Кәрим буенча яшәп, Сөннәткә ышанмау — үзе үк Коръәнгә каршы килү, чөнки Коръәни Кәрим пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм Сөннәтенә ияреп гамәл кылу тиешле икәнен раслаучы күп кенә аятьләрне үз эченә җыйган. Бу китапта автор, Сөннәтне читкә кагып, ялгыш фикер йөртүчеләргә төгәл җаваплар һәм дәлилләр китерә.




**Китапны «Хозур» нәшрият йорты кибетләрендә сатып алырга һәм җир йөзенең теләсә кайсы почмагыннан заказ бирергә мөмкин.**
**Кибет:** Казан шәһ., Париж коммунасы ур., 6нчы йорт.
Тел.: +7 960 072-74-63;
**Склад:** Казан шәһ., Газовая ур., 14нче йорт.
Тел.: +7 (966) 250-00-09;
**Интернет-кибет:** huzurshop.ru

РЕКЛАМА 12+

хәлифәлек иткән чорда яңа ачкыч ясала. Иске ачкыч Истамбул шәһәренең Топкапы сарае музеенда саклана.

### 3. РӘХМӘТ УЛАГЫ (МИЗАБ ӘР-РАХМӘ)

Рәхмәт улагы – Кәгъбәтуллаһ түбәсенең ян өлешенә беркетелгән, яңгыр суларын Хәтим мәйданына төшерүче улак. Хаҗәр анабыз белән Исмәгыйль галәйһиссәлам күмелгән урынга юнәлдерелгән булганга күрә, аны Рәхмәт улагы дип атаганнар. Озынлыгы – 2,53 м, киңлеге – 26 см. Рәхмәт улагы – изге Кәгъбәтуллаһның иң кечкенә, ләкин иң матур, фазыйләтле өлешләренең берсе. Элеккеге вакытта ул агач, көмеш һәм корычтан эшләнгән булган. Хәзерге вакытта тышы чиста алтыннан, эчке аскы катламы көмештән эшләнгән.

Кошлардан саклану өчен, улак кырыйларына сөңгеләр беркетелгән. Ләкин Рәхмәт улагына да, Кәгъбә түбәсенә дә кошлар кунмый, Изге йортны нәҗесләми. Бу – Аллаһы Тәгаләнең бер могҗизасы булып тора.

Улактан агып төшкән яңгыр суы Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән шифалы, дәвалау үзлегенә ия су булып санала.

Улак астында Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең дога кылганы билгеле. Тәваф кылучы мөселманнарның Рәхмәт улагы урнашкан бу изге урынга игътибарлы булулары кирәк. Рәхмәт улагы астында кылган догалар кабул була.

### 4. ШӘЗАРВАН (ЦОКОЛЬ)

Шәзарван – Кәгъбәтуллаһның дивардан Мәтафка чыгып торган диварының нигезе. Ташкын сулары үтеп кермәслек итеп, 1627 елны мәрмәрдән төзелгән. Биеклеге – 13 см, киңлеге 45 см.

### 5. ИСМӘГЫЙЛЬ ХИҖРӘСЕ (ХАТЫЙМ)

Исмәгыйль хиҗрәсе – Кәгъбәтуллаһка кушылып торучы 3 м озынлыктагы ярымай формасындагы урын. Аны шулай ук «Хатыйм» дип тә атыйлар. Хатыйм диварының биеклеге – 1,32 см. Исмәгыйль галәйһиссәлам һәм Хаҗәр анабыз шушы җирдә җирләнеп.

Корәешләләр үзгәртеп корган вакытта бу урын Кәгъбәдән аерылса да, Кәгъбәнең бер өлеше булып санала. Монда кылган догалар кабул була.

### 6. МҮЛТӘЗӘМ

Кара таш белән Кәгъбәтуллаһ ишеге арасындагы урын. Ул 2 м араны тәшкил итә. Догалар кабул була торган урын. Бу урында Изге Йорт диварына яңаклар, күкрәк, кул тиярлек итеп сыенып тору сөннәт санала. Габдулла бине Гомәр: «Мин Расүлуллаһның шулай эшләгәнен күрдем»,– дип әйткән (Ибне Мәҗе).

### 7. ИБРАҺИМ МӘКАМЕ

Кара таштан 14,5 м ераклыкта урнашкан. Ибраһим мәкаме – Кәгъбәтуллаһның диварын өйгәндә Ибраһим пәйгамбәрнең басып торган, аның аяк эзләре төшеп калган 20 см биеклегендәге саргылт-кызыл таш.

Ташта уелып калган эзнең тирәнлеге 10 см (икенчесе 9 см). Озынлыгы – 22 см, киңлеге – 11 см. Бармак эзләре сакланмаган.

Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең аяк эзләре Ибраһим галәйһиссәламнең аяк эзләре белән тәңгәл килгән. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Ибраһим галәйһиссәламнең барлык нәселе арасыннан мин аңа иң нык охшаганы», – дип әйткән булган (әл-Бохари).

Зур булмаган бу таш Кәгъбәнең диварларын күтәргәндә төзелеш лифты вазыйфасын башкарган. Бу Аллаһы Тәгаләнең көчен-кодрәтен күрсәтүче ачыктан-ачык могҗиза булган. Ибраһим мәкаменең бүгенге көннәргә кадәр саклануы, кешеләрнең җәһилият чорында да аңа ташларга табынган кебек табынмаулары бу мөбарәк ташның Аллаһы Тәгалә тарафыннан сакланган булуын күрсәтә.

Баштагы чорда Ибраһим Мәкаме тәрбә эчендә булган. 1967 елны, тәвафтагы барлык корылмалар сүтелгәч, Ибраһим галәйһиссәламнең аяк эзләре сакланган мөбарак ташны алтын төсендәге нык пыяла гөмбәз эченә күчереп куялар.

Аллаһы Тәгалә Ибраһим пәйгамбәргә бик зур хөрмәт күрсәткән. Аның мөбарәк исеме Коръәндә 69 тапкыр искә алына. Коръәни Кәримнең 14нче сүрәсе «Ибраһим» исемен йөртә. Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламне Хәлил – Аллаһы дусты дип атый. Көненә, иң кимендә, 5 тапкыр, дөньяның барлык мөэминнәре, намазда (әт-тәхияттә) Ибраһим пәйгамбәрнең исемен кабатлый.

### 8. КАРА ТАШ ПОЧМАГЫ

Кәгъбәтуллаһның көнчыгышында урнашкан мөбарәк почмак. Монда «Кара таш» урнаштырылган.

### 9. ЙӘМӘН ПОЧМАГЫ (РӨКЕН ЙӘМӘНИ)

Кәгъбәтуллаһның көньягында, Йәмән ягына караган почмак. Кара ташның капма-каршы ягында урнашкан. Риваятьләрдә килгәнчә, Кәгъбәнең бу мөбарәк почмагы бүгенгә кадәр Ибраһим галәйһиссәлам вакытындагы нигез өстендә утыра. Габдулла бине Габбас Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең аңа «истиләм» кылганы турында әйткән (Тирмизи). Истиләм кылу, ягъни кул тию яки үбү белән әлеге почмакка кагылу – сөннәт гамәл. Мөҗәһид: «Куллар Рөкен Йәмәнигә кагылганда кылынган дога кабул була», – дигән. Расүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм Йәмән почмагы белән Кара таш арасында «Раббәнә» догасын укыган, безнең өчен дә шулай эшләү сөннәт булып тора.

### 10. ШАМ ПОЧМАГЫ (РӨКЕН ШӘМИ)

Кәгъбәтуллаһның көнбатышка, Сүрия ягына караган почмагы.

### 11. ГЫЙРАК ПОЧМАГЫ

Кәгъбәтуллаһның төньякка, Гыйрак ягына караган почмагы.

### 12. КӘГЪБӘ ЯПМАСЫ

Кәгъбә япмасы – Коръән аятьләре чигеп язылган Кәгъбәтуллаһны барлык ягыннан да әйләндереп алган кара ефәк япма. Изге йортны пычранудан саклау өчен кулланыла. Махсус фабрикада тукыла. Озынлыгы 658 м. Бер япма әзерләү өчен 670 кг югары сыйфатлы табигый ефәк, 150 кг алтын һәм көмеш тотыла. Япма ел саен хаҗ аенда алыштырыла. Чорына күрә ул кызыл, яшел һәм ак төстә булган.

Япманың өске өлешендә 4 якны да әйләндереп алучы декоратив пута бар. Ул япманың гүзәллеген арттыру өчен өстәлә. Анда эчке һәм тышкы яклап: «Тәүбә юлы ачык, Аллаһыдан гафу сорагыз, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өметегезне өзмәгез, чынлыкта Аллаһы – Гафу итүче, Мәрхәмәтле» эчтәлегендәге аятьләр чигеп язылган.

### 13. ИБРАҺИМ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ БАСЫП ТОРГАН ҖИР

Кәгъбәтуллаһның диварын өйгәндә Ибраһим пәйгамбәрнең басып торган урыны.

**Гүзәлия Сәйфуллина**

# АЗАННЫҢ АСЫЛЫ НӘРСӘДӘ?

Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә күченгәннән соң, киң җәмәгатьчелеккә намаз вакыты җитү турында хәбәр итү һәм намазга өндәү ысулы булмый. Шундый төр авырлык белән очрашкан сәхабәләр бу хәлдән чыгу юлын уйлый башлыйлар.

### БАРЛЫККА КИЛҮЕ

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм һәр мәсьәләдә дә Аллаһыдан хәбәр, ягъни вәхи көткән. Ә азан әйтү турында аңа бер хәбәр дә килмәгән. Шул чакта ул Коръән Кәримдәге: «Эшләреңдә иптәшләрең белән киңәшләш», – дигән аятькә таяна һәм иптәшләре белән киңәшләшә.

Сәхабәләр тарафыннан төрле тәкъдимнәр яңгырый. Кемдерчаң кагырга кирәк, ди. Икенче берәүләр, башка дин вәкилләренә охшамас өчен, чаң кагу идеясеннән баш тартып, боргы кычкыртырга тәкъдим итәләр. Өченче берәүләр байрак эләргә һәм шулай итеп, якын-тирәдәге кешеләргә намаз вакыты җитүен хәбәр итәргә тели. Ләкин иртәнге һәм ястү намазларының вакыты караңгы чакка туры килеп, байраклар күренми калу ихтималы булганлыктан, бу идеядән дә баш тарталар. Бу төр фикер алышулар, бәхәсләр, бернинди нәтиҗәгә дә китерми, һәм сәхабәләр таралышалар.

### ТӨШ

Шул төндә Абдулла бин Зәед радыйаллаһу ганһе төш күрә. Аңа бер фәрештә азан сүзләрен өйрәтә. Ул уяну белән иртәнге намазга кадәр моны пәйгамберебез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә барып сөйли. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә: «Бу турыда миңа да хәбәр килде», – ди. Төшнең дөреслеген Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм дә дәлилли һәм Җәбраил галәйһиссәламнең аңа намазга чакыра торган сүзләр өйрәтүе турында хәбәр итә. Ул Билал Хәбәшигә барып сүзләрен өйрәтергә һәм иртәнге намаз алдыннан укырга куша. Шулай итеп, Билал Хәбәши азанчы-мөәзин була. Ул азанны бик матур әйткән, ди, хәбәр итәләр.

Шул көннән башлап, намазга – Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәткә чакыра торган сүзләр бер тапкыр да үзгәртелми.

*Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм: «Азан укуның савабы шулкадәр күп, аны белсәгез, азан уку өчен бер-берегез белән ярышып, арагызга шобага салып, азан укыр идегез», – дигән.*

### АЗАН – УЛ...

Азан – кешеләрне намазга, Аллаһы белән очрашуга чакыру сүзләре. Азан кешеләргә намаз вакыты җитүе турында хәбәр итә, бу Аллаһыга шөкер итүнең иң яхшы ысулы, чөнки азан сүзләрендә чакыру гына түгел, ә Аллаһы Тәгаләнең бөеклеге, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең Аның колы һәм Расүле булуы турында хәбәр итү сүзләре дә бар.

Азан – ул Исламның үзе хакында тирә-юньгә белдерүе, ул мөселманның ирекле икәнен күрсәтә. Азан ул Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм чакыруының дәвамы һәм бу чакыру ахырзаманга хәтле барачак. Азан кешегә нәрсәгә омтылырга, ничек яшәргә кирәклегенә юл күрсәтә. Азан ул бөтен дөньяга Аллаһының берлеге, Аның бөеклеге хакында һәм Аллаһыдан башка табынырга лаеклы һичбер нәрсәнең юклыгын искә төшерә.

Азан – Аллаһының безгә булган рәхмәтедер. Төрле манаралардан яңгыраган азаннарны ишеткәч, кеше күңелендә бер рәхәтлек һәм тынычлык сизә, борчу-мәшәкатьләрен оныта.

### АЗАН СҮЗЛӘРЕ

**Аллаһу әкбәр** (мәгънәсе: Аллаһы Тәгалә һәр нәрсәдән олуграк), 4 тапкыр.

**Әшһәду әл-ләә иләһә илләл-лааһ** (мәгънәсе: Күңелемнән гуаһлык бирәмен ки, дөреслектә, Аллаһы Тәгаләдән башка Илаһи зат һич юк), 2 тапкыр.

**Әшһәду әннә Мүхәммәдәр-рәсүүлүл-лааһ** (мәгънәсе: Күңелемнән гуаһлык бирәмен ки, дөреслектә, Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вә сәлләм – Аллаһы Тәгаләнең илчесе), 2 тапкыр.

**Хәййә галәс-саләәһ** (мәгънәсе: Ашыгыгыз намазга), 2 тапкыр.

**Хәййә галәл-фәләәх** (мәгънәсе: Ашыгыгыз газаптан котылырга), 2 тапкыр.

**Аллаһу әкбәр** (мәгънәсе: Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәдән олуграг), 2 тапкыр.

**Ләә иләһә илләл-лааһ** (мәгънәсе: Бер Аллаһы Тәгаләдән башка Илаһи зат һич юк), 1 тапкыр.

Иртәнге намаз азагында Хәййә галәл-фәләх дигәннән соң, 2 тапкыр Әс-саләәтү хайрүм-минән-нәүм (Дөреслектә, намаз уку йокыдан яхшырак), дип әйтү тиеш.

### АЗАН ӘЙТҮЧЕ ҺӘМ ТЫҢЛАУЧЫ НӘРСӘЛӘРНЕ БЕЛЕРГӘ ТИЕШ?

Мөәзингә, ягъни азан әйтүче кешегә тәһарәтле булу, кыйблага каршы аягүрә тору, ишарә бармакларын колак очларына кую, азанның сүзләрен ачык итеп, сузып, ике сүзне бергә кушмыйча, һәрберсен аерып әйтү, «Хәй’йә галәс-саләәһ» дигән сүзләрне уң якка таба карап һәм «Хәй’йә галәл-фәләәһ» дигән сүзләрне сул якка карап әйтү – (мөстәхәб).

Азан әйткәнне ишеткән кешегә йөрүдән, эштән, ашаудан туктап, сөйләшмичә, мөәзин артыннан азан сүзләрен кабатлау – мөстәхәб.

Мөәззин «Хәй’йә галәс-саләәһ» дигәч, «Ләә хәүлә вә ләә куввәтә илләә билләәһил-галий’йил-газыйм», ягъни «Һәрбер хәл һәм куәт – олуг Аллаһы Тәгаләдән генә», – дип әйтү дөрес булыр.

Мөәзин «Хәй’йә галәл-фәләәһ» дигәч, «Мә шә’әллаһу кәәнә вәмәә



Фото авторы: Seva_blsv / elements.envato.com

ләм йәшә'ләм йәкүн», ягъни «Аллаһы Тәгалә теләгән эш һич булмый калмас һәм Ул теләмәгән эш һич булмас», – дип әйтү – мөстәхәб.

### АЗАННАН СОҢ НИНДИ ДОГА УКЫРГА?

اَللّٰهُمَّ رَبَّ هَذِهِ الدَّعْوَةِ التَّامَّةِ وَالصَّلَاةِ
الْقَائِمَةِ آتِ مُحَمَّدًا الْوَسِيلَةَ وَالْفَضِيلَةَ
وَالدَّرَجَةَ الْعَالِيَةَ الرَّفِيعَةَ وَابْعَثْهُ مَقَامًا
مَحْمُودًا الَّذِى وَعَدْتَهُ وَارْزُقْنَا شَفَاعَتَهُ يَوْمَ
الْقِيَامَةِ إِنَّكَ لَا تُخْلِفُ الْمِيعَادَ

**«Аллааһүммә раббә һәәҙиһид-дәгъвәтит-тәәммәти вәс-саләәтил-каа'имәһ. Әәти Мүхәммәдәнил-вәсииләтә вәл-фәдыйләтә вәд-дәраҗәтәл-гаалийәтәр-рафиигәһ. Вәбъгәс'һү мәкаамәм-мәхмүүдәнил-ләҙии вәгадтәһү вәр-зүкнәә шәфәәгатәһү йәүмәл-кыйәәмәһ. Иннәкә ләә түхълифүл-миигаадь».**

*«Әй, шушы камил азанның һәм вакыты кергән намазның Хуҗасы Аллаһы Тәгалә. Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә ярдәмне, артыклыкны һәм югары дәрәҗәне бир. Шулай ук аны Үзең вәгъдә кылган мактаулы урынга ирештер һәм Кыямәт көнендә аның шәфәгатен безгә насыйп ит. Дөреслектә, Син Үз вәгъдәңә хилафлык кылмыйсың».*

### АЗАННЫҢ НИНДИ ШАРТЛАРЫ БАР?

1. Намазның вакыты керү.
2. Ир кеше әйтү.
3. Азанның гарәп телендә булуы.
4. Азанны кешеләр ишетерлек итеп кычкырып әйтү.
5. Азан сүзләрен тәртип белән әйтү.
6. Кыйблага каршы тору.
7. Азан әйтүченең акыллы һәм мөселман булуы.
8. Азан әйтүченең госелле булуы.

### АЗАННЫҢ МӘКРУҺЛАРЫ

1. Азанны ике тапкыр кабатлап әйтү.
2. Олы гөнаһлар кылучының азан әйтүе.
3. Азанны сәбәпсез утырып әйтү.
4. Азан һәм икамәт әйткәндә бүленеп башка бер сүз әйтү.
5. Азанны җырга әйләндерү.

*Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм әйтте: «Азан белән икамәт арасындагы дога кире кагылмас» (Нәсаи, Ибн Хузәймә)*

### НӘРСӘ УЛ КАМӘТ?

Камәт тә азан кебек әйтелә. Камәттә фәкать Хәййә галәл-фәләх дигәннән соң 2 тапкыр «Кадъ каамәтис-саләәһ (Дөреслектә, намаз укыла башлады)», – дип әйтергә кирәк. Камәт азанга караганда тизрәк әйтелә. Азан һәм камәт әйтү ирләргә генә тиешле.

**Айгөл Абдрахманова**

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ
№ 10 (339) октябрь, 2023 | Рабигыль-әүвәл– Рабигыль-ахыр, 1445

# Аллаһы Тәгаләнең Әл-Бари исеме нәрсәне аңлата?

**Раббыбыз Аллаһы – бер, әмма аның күп кенә искиткеч исемнәре бар. Кешеләргә билгеле булганнары бары тик туксан тугыз – Әл-Әсма вәл-Хөснә. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Дөреслектә, Аллаһының 99 исеме бар, кем шуларны санап чыга, шул җәннәткә керә. Ул – бер һәм так санны ярата» (Мөслим).**

Аллаһы Тәгаләнең һәр исеме – безнең Аны яратуыбызны һәм Аның турындагы гыйлемнәребезне арттыра торган сыйфатлар. Без Раббыбыз Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләне Аның шушы күркәм сыйфатлары аркылы танып беләбез һәм Аңа шөкерләребезне белдерүдән туктамыйбыз.



Рәсем авторы: Calligraphy Vector Tracer / https://www.shutterstock.com/

*Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтә: «Аллаһы, Аннан башка һичбер илаһ юк! Иң күркәм исемнәр – Аныкы гына». «Та һа», 20:8*

Әлеге язмада Аллаһының Әл-Бари исеме белән якыннанрак танышып китәрбез. Раббыбызның әлеге сыйфаты Яратучы, юктан бар Кылучы, Булдыручы дигәнне аңлата.

Аллаһы Сөбеханәһу вә Тәгаләнең һәрбер нәрсәгә көче җитә. Ул үзенең чиксез булган көче белән бернинди авырлыксыз шушы дөньяларны, һәркайсының бу дөньяда үз урыны булган мәхлукларын яратты. Аның өчен авыр булмаган әлеге процесс беркайчан да тукталмый. Аның «Бул!» – диюе җитә һәм ул була.

Әс-Сануси: «Әл-Бари – ул Үзенең барлыкка китергәннәренә, барлык терек һәм терек булмаганнарга тәэсир итүче, аларга кыяфәт бирүче», – дигән.

Әлеге сыйфат бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә кагыла һәм Аннан кала беркем дә юктан бар кыла алмый. Кешеләр ясаган предметлар да шулай ук Аллаһы Тәгалә булдырганнардан ясала.

Аллаһы Тәгалә яраткан әйберләр барлык кимчелекләрдән дә пакь. Әгәр дә Ул теләсә, шулай ук кимчелекләр белән ярата. Раббыбыз Үзенең гыйлеме, зирәклеге һәм көче белән җир йөзендәге барлык әйберләрне сокланырлык кыяфәттә яратты.



Фотоның авторы: Rawpixel / elements.envato.com

### КОРЪӘНДӘ КИТЕРЕЛӘ:

***«Ул Аллаһы –** [һәрнәрсәне бер хикмәт белән] **Барлыкка китерүче,** [кимчелекләрсез] **Бар итүче,** [бар нәрсәгә] **калып, рәвеш бирүче. Иң күркәм** [мәгънәләрне белдергән] **исемнәр дә – Аныкы. Күкләрдә һәм җирдә булучылар Аны** [мактап] **тәсбих итә. Ул Бөек** [Җиңелмәс], **Хикмәт иясе».***

*«Әл-Хәшр / Җыен», 59:24*

Аллаһы Тәгаләнең һәр исеме яхшы һәм һәр исеме – Аны тану юлларын җиңеләйтүче сыйфат. Әлеге исем аркылы һәр мөселман кешесе бу дөньяда булган һәр нәрсә Аллаһы Тәгаләдән икәнен аңлый. Ул – һәр нәрсәне барлыкка китерүче. Әл-Бари исеме мөэмин мөселманда бик мөһим бер сыйфатны: Аңа ихластан итагать итүне һәм Аңа гына тәвәккәл кылу сыйфатын тәрбияли.

**Газиз Булатов**

# ГАРИФ ГАЛИЕВ: «Иҗат яшәтә...»


Фотоның авторы: stokkete / elements.envato.com

### БАЛАЧАК КАЯ ИЛТӘ?!

Гариф Закир улы Галиев 1903 елның 10нчы маенда хәзерге Азнакай районы Урманай авылында вак сәүдәгәр гаиләсендә туган. Әтисе кинәт үлеп киткәч, 7 яшьлек Гарифны Бәйрәкә авылы мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Ул анда 1918 елга кадәр укый. Мәдрәсә җәдит ысулындагы уку йорты булганлыктан, Гариф дөньяви фәннәрдән дә беркадәр белем ала. Шуңа өстәп, үзлегеннән өйрәнә, матур әдәбиятны бик яратып укый.

1917 елгы Бөек Октябрь революциясе мәдрәсә шәкертләрен дә канатландырып җибәрә. Алар, мәдрәсә каршында һәвәскәр драма түгәрәге оештырып, тирә-як авылларда спектакльләр куеп йөри башлыйлар. Шунда яшүсмер Гариф иң актив «артистларның» берсе була. Бу мавыгуын ул 1918 елның көзендә Бөгелмә шәһәрендә ачылган өч еллык укытучылар семинариясенә кереп укый башлагач та ташламый, семинариядәге сәнаигы нәфисә (әдәбият-сәнгать) түгәрәгенә йөреп, рухи омтылышларына азык таба. Ләкин 1921 елгы дәһшәтле ачлык чорында Г. Галиев семинарияне ташлап, туган авылына кайтып китә.

### ЮЛ БАШЫ...

Шул чорда Г.Галиев Казанда чыга торган «Крестьян гәзите»ндә яза башлый, анда үзенең авыл тормышына караган кыска-кыска очеркларын, хәбәрләрен бастыра. 1925 елда Г.Галиевне Кызыл Армия хезмәтенә алалар. Шул ук елның 11нче ноябрендә Мәскәүдә чыга торган «Эшче» газетасында аның «Вәли ничек кызылармеец булды» исемле беренче хикәясе дөнья күрә.

1926 елда, армия хезмәтеннән кайткач, Г.Галиев туган авылындагы зурлар өчен ачылган кичке мәктәптә укыта, 1927–1928 елларда Азнакай урта мәктәбендә эшли. Шул чорда язучы Мәхмүт Максуд, яшь авторның «Эшче»дә басылган барлык хикәяләрен туплап, 1927 елда «Кызыл Армия хикәяләре» исеме белән өч табак күләмендәге мөстәкыйль җыентыгын бастырып чыгара.

1928 елның көзендә Г.Галиевне Бөгелмәдә чыга торган «Сабанчы» газетасы редакциясенә эшкә чакырып алалар. 1931 ел башында Казанга күчеп, «Колхоз газетасы» редакциясендә җаваплы секретарь булып эшли башлый. 1935 елдан Бөек Ватан сугышы башланганчы «Колхоз бригадиры» дигән журнал редакциясендә җаваплы секретарь булып эшли. Утызынчы еллар дәвамында Г.Галиевнең әдәби иҗат эше аеруча активлаша, 1931-1941 еллар эчендә аның *9 китабы* дөнья күрә. Алар арасында «Фамилиясез кеше», «Бибкәй аланы» кебек заманында популярлык казанган повестьлар һәм очерк җыентыклары бар. 1939 елда Гариф Галиевне СССР Язучылар союзы әгъзасы итеп алалар (рекомендациянең берсен аңа М.Җәлил бирә).

### СУГЫШ ЕЛЛАРЫ

Бөек Ватан сугышы башлангач, Г. Галиев 1941 елның августыннан 1946 елның апреленә кадәр армия хезмәтендә була. Хәрби заданиеләрне үрнәк рәвештә үтәгәне өчен, ул ***Кызыл Йолдыз ордены, «Варшаваны азат итү өчен», «Берлинны алу өчен»*** медальләре белән бүләкләнә. Сугыштан соңгы елларда Г. Галиев «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясендә өч ел очеркист, 1949 елның августыннан 1958 елның маена кадәр, «Колхоз бригадиры» журналының җаваплы редакторы булып эшли.

### ИҖАТ...

Г.Галиевнең әдәбияттагы төп темасы – авыл, анда булган тарихи вакыйгалар, үзгәрешләр, аның үткәне һәм бүгенгесе. Үзенең күп санлы хикәя һәм очеркларында ул авыл хезмәт иясенең тарихи шартларда үзгәрүен, рухи үсешен күрсәтергә омтыла. Аның әсәрләре тормыш материалына бай һәм идея-эчтәлек ягыннан актуаль булуы белән аерылып тора. Г.Галиев балалар әдәбиятында һәм драматургия жанрында да нәтиҗәле эшли. Аның дистәдән артык бер пәрдәле пьесалары бар. Авторның «Хаттан башланды» исемле бер пәрдәле комедиясе, аеруча уңыш казанып, өч мәртәбә (1949, 1952, 1954) рус һәм немец телләрендә (1956, Дрезден) басылып чыга.

Гариф Галиев 1985 елның 22нче мартында Казанда вафат була.

**«Татар дин әһелләре»** китабыннан

ДИН вә мәгыйшәт
№ 10 (339) октябрь, 2023 | Рабигыль-әүвәл– Рабигыль-ахыр, 1445

# СӨННӘТЧЕ БАБАЙ

*(Дәвамы. Башы алдагы санда)*

Ул, өйлә намазыннан соң тәһарәте кыстар төсле кеби тоелганга, өйгә кайтып тәһарәтләнеп барырга уйлап, өйгә таба борылды. Күрше йортка көзге ат көтүе бирергә җыелган җыен янына килеп, сәлам биреп, мәсҗед картлары берлән сөйләшеп, акыртын гына өенә юнәлде. Ишекне ачты. Түр башында карчыгының бәрәңге арчып утырганыны күрде. Күзе карчыкның кулындагы былчыранып беткән пәкегә төште. Аның кулында сөннәт пәкесе икәнене күреп, элгәре катып калды, ахырдан ул җенләнгән кеби булды: кычкырырга, бакырырга тотынды, кулы берлән бәреп җибәреп, пәкене алды, үзе кычкырып егъларга тотынды. Аңар әллә кайдан көч керде. Кычкырып-кычкырып тиргәргә, кулы берлән бутанырга башлады:

– *Чык өемнән, бәдбәхет, чык өемнән! Сәлман Фарси пәкесе, Сәлман Фарси пәкесе! Ни диермен?! Кыямәт көнне ни җавап бирермен?!* – дип, егъларга, карчыкның кулына очраган сандыгыны, комганыны, ястыгыны йортка ыргытырга тотынды, тагы кычкырды, тагы бакырды, тагы егълады. Елан чаккан кеше кеби, кая барырга белмәде, егълап урамга чыкты. Күршедәге халыкка: *«Җәмәгать, җәмәгать!»* – дип бик каты иттереп кычкыра башлады. Бөтен җыен, утфәлән бар дип, бабайга таба ашыкты. Бабай:

– *Менә, җәмәгать, хәзрәти Сәлман Фарси пәкесе!.. Җитмеш мең мөселманның сөннәткә утыртылган пәкесе!.. Хәзрәти Аксак Тимердән калган пәке ул!..*

Ул, шул сүзне әйткәндә, өенә төртеп күрсәтте:


– *Шул пәке берлән, хәзрәти Сәлман Фарси пәкесе берлән бәрәңге арчый!..* – диде дә тагы егъларга тотынды.

Халык бабайны төрлечә бастырырга теләсә дә, бабай һаман кызганнан-кызды. Ул бөтенләй тилергән кеби булды. Ул, өенә таба барып, йорттагы карчыгыны күреп:

– *Кит, шайтан!.. Гөнаһ шомлыгы, Иблис сидеге, пәри ташландыгы, күземә күренмә!.. Талак син, талак син!..* – дип кычкырды.

Халык тагы бабайны бастырырга теләсә дә, ул кычкырып егъларга тотынды. Тагы әйләнеп карап, карчыкның йорт уртасында торганыны күреп, тиздән сикереп торып:

– *Әле китмәде, шайтан! Дәҗҗал! Яэҗүҗ-Мәэҗүҗ колы!* – дип, барып



Фотоның авторы: Ravil Sayfullin / shutterstock.com

казык алып сугарга күтәрде. Бер кеше, бабайны кочаклап алып, сугудан саклый алды. Карчык урамга чыгып качты. Бабай аның артыннан ястыгыны, сандыгыны, комганыны, туп уйнаган малай кеби, берсе артыннан берсене ыргыта башлады. Ул тагы егълады, тагы:

– *Сәлман Фарси, шәфагать кыл! Карчыгым бәддогасы, карчыгым бәддогасы!..* – дип, халыкка кайгысыны аңлатырга тотынды.

Ләкин теге карчык тагы йортка керергә өлгерә алмады, ул тагы сикереп торып казыкны күтәрде. Бу юлы сугарга да өлгерде, ләкин карчык качып өлгерде. Ул тагы кызды, тагы кычкыра башлады. Кулындагы пәкесене кысып, тагы әллә ниләр сөйләргә тотынды. Картлар, аны бастырыр өчен, төрле сүзләр сөйләргә тотындылар. Ул берсене дә ишетмәде.

Менә бердән аның кып-кызыл бите агарды. Ул калтырана башлады. Ап-ак булып авызыннан күбеге агып, һушсыз булып егылды. Хәзрәт килеп Коръән укыганнан соң аның һушы килсә дә, теле ачылмады. Пәкене никадәр алырга теләсәләр дә, кулыннан ычкындырмады. Хәзрәт килгәч, ул күзе берлән әллә нәрсә эзләнә башлады, кунакларга әллә нәрсә әйтергә теләде, ләкин әйтә алмады.

Өченче көнне хәзрәт, Коръән укып бетереп, янында утырып торганда: *«Әти, кунаклар килде!»* – дип, әтисене чакырып мәхдүм килеп керде. Бабайның күзе нурланды; ул көлгән кеби булды; әллә нәрсә әйтергә телэгәне беленде, күзе берлән мәхдүмне чакырган кеби булды. Мәхдүм акыртын гына әтисе янына килде. Бабай тагы, күзене әллә нинди мәгънәләр чыгарып, кулын селкетә башлады. Мең бәла берлән кулыны күтәреп, мәхдүмгә таба төртте. Һәммә кешегә мәхдүмгә пәкесен, үзенчә, иң кыйммәтле булган мирасыннан – Сәлман Фарси пәкесене бирергә теләвене аңлатты. Мәхдүм аптырап калды. Хәзрәт алырга кушты. Алды. Бабайның йөзенә көләчлек чыкты. Ул әллә нигә шатланган кеби булды. Тагы бик авыраеп: *«Алла!..»* – диде дә үлде.

Үзе казыган кабергә иртәгесен бөтен авыл җыелып күмде. Күрше карты аның өстенә дә каен илтеп утыртты. Ике каен бер-берсе берлән бәрелә-бәрелә, сөйләшә-сөйләшә үсә башладылар.

Көзге ягъмурлы җилдә өйнең сылаганы изрәп, ул да җимерелде. Усал сыерлар, канауны җимереп, бакчага кереп йөргәнгә, түтәлләр, бакчалар да кешелектән чыкты. Кызыл миләшләрне җыяр өчен, бөтен урам малайлары миләшнең ботакларыны сындырып бетергәнгә, ул да икенче елны яфрак ярмады. Корыды.

Бер ике-өч елдан Сөннәтче бабайның йорты урынында тормыш галәмәтеннән бернәрсә дә калмады. Ләкин зияраттагы ике картайган, черегән, беткән картларның өстенә ап-ак тузлы, ямь-яшел яфраклы яшь ике каен үсте. Алар зурайды, биекләнде, түгәрәкләнде; тавышлы-тынлы, кешеләр аңламый торган тормыш берлән яши башладылар.

Бер тормыш бетте, бер тормыш башланды...

1911

**Гаяз Исхакый** әсәреннән

## ДҮШӘМБЕ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55** «Минбар» 12+
**08:20,17:00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**08:40,17:30** «Бермәчеттарихы» 12+
**08:55,17:45** «1001 хәзинә» 12+
**09:10,18:00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев 12+
**09:35,18:25** «Фикер» 16+
**10:20,19:15** «Бер хәдис – бер җавап» 12+
**10:45,19:40** «Коръән могҗизалары» 12+
**11:00,19:55** «Дин турында» 12+
**11:30,20:30** «Хикмәтле хикәяләр» 12+
**11:40,20:40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен) 12+
**12:00** Азан 0+
**12:05,21:00** Мультфильмы 6+
**12:20,21:15** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12:35,21:30** «Онлайн медресе: Тафсир» 12+
**13:10,22:05** «Знамения Корана в свете современной науки» 12+
**13:25,22:20** «Узнаем у имама» 12+
**14:10** «Разговоры о важном» 12+
**14:15,** 23:05 «Алифба» 12+
**14:35** «Есть вопрос – есть хадис» 12+
**15:00,23:25** Ислам без стереотипов 12+
**15:20,23:45** Почитайка 0+
**15:35** «Тайна» 12+
**15:55** «Халяль-лайфстайл» 12+
**16:15** «Рухуль Байян» 12+
**16:20** «Ислам сегодня» 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## СИШӘМБЕ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55** «Минбар» 12+
**08:30,17:25** «Иң гүзәл исемнәр» 12+
**08:45,17:40** «Ислам мәдәниятенең алтын гасыры» 12+
**09:00,17:50** «Рисәлә» 12+
**09:15,18:05** «Миллият сүзлеге» 12+
**09:35,18:25** «Рухел Бәйән» 12+
**09:45,18:35** «Татарлар тарихы» 12+
**10:30,19:25** «Тәмле булсын» 12+
**10:50,19:45** «Имамнан сорыйк» 12+
**11:40,20:40** «Намазга өйрәник» (ир-атлар өчен) 12+
**12:00** Азан 0+
**12:05,21:00** Мультфильмы 6+
**12:20,12:20** Вера в предопределение 12+
**12:30,21:25** «Онлайн медресе: Сира» 12+
**13:05,22:00** «Дети в саду пророчества» 12+
**13:25,22:20** «40 хадисов – 40 толкований» 12+
**14:00,22:55** «Узнаем у имама» 12+
**14:45,23:40** «Халид бин Валид» 12+
**15:40** «Познай свою религию» 12+
**16:00** «Ислам сегодня» 12+
**16:40,00:35** «Поучительные истории» 12+
**16:45,00:40** «Хафтияк Шариф» 12+
**17:00** «Мәслихәт» 12+
**20:35** «Гыйбрәтле хикәяләр» 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ЧӘРШӘМБЕ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55** «Минбар» 12+
**08:20,17:00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**08:40** «Бер мәчет тарихы» 12+
**08:55,17:45** «1001 хәзинә» 12+
**09:10,18:00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев 12+
**09:35,18:25** «Бәрәкәтле гаилә» 12+
**10:20,19:15** «Бер хәдис – бер җавап» 12+
**10:45,19:40** «Коръән могҗизалары» 12+
**11:00,19:55** «Дин турында» 12+
**11:30,20:30** «Хикмәтле хикәяләр» 12+
**11:40,20:40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен) 12+
**12:00** Азан 0+
**12:05,21:00** Мультфильмы 6+
**12:15,21:10** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12:30,21:25** «Онлайн медресе: Таджвид» 12+
**12:55** «40 хадисов – 40 толкований» 12+
**13:30,22:05** «Узнаем у имама» 12+
**14:20,21:50** «Знамения Корана в свете современной науки» 12+
**14:35,22:55** «Есть вопрос – есть хадис» 12+
**15:00,23:20** Ислам без стереотипов 12+
**15:20,23:40** Почитайка 0+
**15:35,23:55** «Тайна» 12+
**15:55,00:15** «Голос разума» 12+
**16:30,00:50** «Рухуль Байян» 12+
**16:35** «История ислама в России» 12+
**17:30** «Хаҗ кылырга өйрәник» 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ПӘНҖЕШӘМБЕ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55** «Минбар» 12+
**08:20,17:00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**08:40,17:30** «Бермәчеттарихы» 12+
**08:55,17:45** «1001 хәзинә» 12+
**09:10,18:00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев 12+
**09:35,18:25** «Фикер» 16+
**10:20,19:15** «Бер хәдис – бер җавап» 12+
**10:45,19:40** «Коръән могҗизалары» 12+
**11:00,19:55** «Дин турында» 12+
**11:30,20:30** «Хикмәтле хикәяләр» 12+
**11:40,20:40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен) 12+
**12:00** Азан 0+
**12:05,21:00** Мультфильмы 6+
**12:20,21:15** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12:35,21:30** «Онлайн медресе: Тафсир» 12+
**13:10,22:05** «Знамения Корана в свете современной науки» 12+
**13:25,22:20** «Узнаем у имама» 12+
**14:10** «Разговоры о важном» 12+
**14:15,23:05** «Алифба» 12+
**14:35** «Есть вопрос – есть хадис» 12+
**15:00,23:25** Ислам без стереотипов 12+
**15:20,23:45** Почитайка 0+
**15:35** «Тайна» 12+
**15:55** «Халяль-лайфстайл» 12+
**16:15** «Рухуль Байян» 12+
**16:20** «Ислам сегодня» 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ҖОМГА

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55** «Минбар» 12+
**08:30,17:25** «Иң гүзәл исемнәр» 12+
**08:45,17:40** «Ислам мәдәниятенең алтын гасыры» 12+
**09:00,17:50** «Рисәлә» 12+
**09:15,18:05** «Миллият сүзлеге» 12+
**09:35,18:25** «Рухел Бәйән» 12+
**09:45,18:35** «Татарлар тарихы» 12+
**10:30,19:25** «Тәмле булсын» 12+
**10:50,19:45** «Имамнан сорыйк» 12+
**11:40,20:40** «Намазга өйрәник» (ир-атлар өчен) 12+
**12:00** Азан 0+
**12:05,21:00** Мультфильмы 6+
**12:20,12:20** Вера в предопределение 12+
**12:30,21:25** «Онлайн медресе: Сира» 12+
**13:05,22:00** «Дети в саду пророчества» 12+
**13:25,22:20** «40 хадисов – 40 толкований» 12+
**14:00,22:55** «Узнаем у имама» 12+
**14:45,23:40** «Халид бин Валид» 12+
**15:40** «Познай свою религию» 12+
**16:00** «Ислам сегодня» 12+
**16:40,00:35** «Поучительные истории» 12+
**16:45,00:40** «Хафтияк Шариф» 12+
**17:00** «Мәслихәт» 12+
**20:35** «Гыйбрәтле хикәяләр» 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ШИМБӘ

**07:00** «Хәерле сәгатьтә» 12+
**07:55** «Минбар» 12+
**08:20,17:00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**08:40** «Бер мәчет тарихы» 12+
**08:55,17:45** «1001 хәзинә» 12+
**09:10,18:00** «Тәфсир». Тимергали Юлдашев 12+
**09:35,18:25** «Бәрәкәтле гаилә» 12+
**10:20,19:15** «Бер хәдис – бер җавап» 12+
**10:45,19:40** «Коръән могҗизалары» 12+
**11:00,19:55** «Дин турында» 12+
**11:30,20:30** «Хикмәтле хикәяләр» 12+
**11:40,20:40** «Намазга өйрәник» (хатын-кызлар өчен) 12+
**12:00** Азан 0+
**12:05,21:00** Мультфильмы 6+
**12:15,21:10** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12:30,21:25** «Онлайн медресе: Таджвид» 12+
**12:55** «40 хадисов – 40 толкований» 12+
**13:30,22:05** «Узнаем у имама» 12+
**14:20,21:50** «Знамения Корана в свете современной науки» 12+
**14:35,22:55** «Есть вопрос – есть хадис» 12+
**15:00,23:20** Ислам без стереотипов 12+
**15:20,23:40** Почитайка 0+
**15:35,23:55** «Тайна» 12+
**15:55,00:15** «Голос разума» 12+
**16:30,00:50** «Рухуль Байян» 12+
**16:35** «История ислама в России» 12+
**17:30** «Хаҗ кылырга өйрәник» 12+
**00:55** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

## ЯКШӘМБЕ

**07:00** «Минбар» 12+
**07:35,17:25** «Шифа» 12+
**08:10,18:00** «Фикер» 12+
**09:00,18:50** «Дин турында» 12+
**09:35,19:20** «Мәслихәт» 12+
**10:00,19:45** «Әхлак сабаклары» 12+
**10:10,19:55** «Балам-багалмам» 12+
**10:35** «Имамнан сорыйк» 12+
**11:25,20:20** «Намазга өйрәник» Ир-атлар өчен 12+
**11:45** «Миллият сүзлеге» 12+
**12:00** Азан 0+
**12:05** «Онлайн медресе: Тафсир» 12+
**12:30,21:25** «Хузур Вояж с Антоном Кротовым» 12+
**12:45,21:40** «Минбар. Истории» 12+
**13:15,22:10** «Ислам сегодня» 12+
**13:55,22:50** «Познай свою религию» 12+
**14:15,23:10** «Узнаем у имама» 12+
**15:00** Ислам без стереотипов 12+
**15:20** Почитайка 0+
**15:35,00:25** «Медицина Пророка» 12+
**16:00,23:55** Короткометражный фильм 12+
**16:25** «40 хадисов 40 толкований» 12+
**17:00** «Онлайн мәдрәсә» 12+
**20:40** «Тәмле булсын» 12+
**21:00** «Онлайн медресе: Сира» 12+
**00:50** Чтение Священного Корана и смысловой перевод 0+

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**

Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе **Камил СӘМИГУЛЛИН;**

«Хозур» нәшрият йорты директоры **Ришат ХӘМИДУЛЛИН;**

ТР МДНнең Шәригать булеге житәкчесе **Булат МӨБАРӘКОВ;**

Татарстанның баш казые **Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**

ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы **Габдулла ӘДҺӘМОВ**

Баш мөхәррир: **Хамматов Л. Г.**
Мөхәррирләр: **Ситдикова Г. Р., Хәбибрахманова И.И., Абдрахманова А.**
Логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Гарифуллин И. Ф.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** izdat@huzur.ru

**ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**НӘШИР:** «Хозур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6нчы йорт).
Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16нчы февралендә 240нчы номер белән теркәлгән.

Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.

Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 000 данә. Заказ № 2594.
График буенча – 23нче октябрь 21.00, гамәлдә – 21.00 сәгатьтә кул куелды.

Газетага ярты елга язылу бәясе – 175,38 сум. Индексы – П4333. Чыгу көне: 25нче октябрь. Казан шәһәренең мәчетләрендә 25нче октябрь көнне таратыла.

# НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

## НОЯБРЬ 2023 / КАЗАН

| Көн | Көн исеме | ИРТӘНГЕ НАМАЗ | | Кояш чыга | ЗӘВӘЛ | ӨЙЛӘ НАМАЗЫ | ИКЕНДЕ НАМАЗЫ | АХШАМ НАМАЗЫ / ИФТАР | ЯСТУ НАМАЗЫ |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | | |
| 01 | Чәрш | 04:42 | 05:18 | 06:48 | 11:27 | 12:00 | 14:11 | 16:04 | 17:49 |
| 02 | Пәнҗ | 04:44 | 05:20 | 06:50 | 11:27 | 12:00 | 14:09 | 16:02 | 17:47 |
| 03 | Җом | 04:46 | 05:22 | 06:52 | 11:27 | 12:00 | 14:07 | 16:00 | 17:45 |
| 04 | Шим | 04:48 | 05:24 | 06:54 | 11:27 | 12:00 | 14:05 | 15:58 | 17:43 |
| 05 | Якш | 04:49 | 05:26 | 06:56 | 11:27 | 12:00 | 14:03 | 15:56 | 17:41 |
| 06 | Дүш | 04:51 | 05:29 | 06:59 | 11:27 | 12:00 | 14:02 | 15:54 | 17:40 |
| 07 | Сиш | 04:53 | 05:31 | 07:01 | 11:27 | 12:00 | 14:00 | 15:52 | 17:38 |
| 08 | Чәрш | 04:55 | 05:33 | 07:03 | 11:27 | 12:00 | 13:58 | 15:50 | 17:36 |
| 09 | Пәнҗ | 04:57 | 05:35 | 07:05 | 11:27 | 12:00 | 13:56 | 15:48 | 17:35 |
| 10 | Җом | 04:58 | 05:37 | 07:07 | 11:27 | 12:00 | 13:54 | 15:46 | 17:33 |
| 11 | Шим | 05:00 | 05:39 | 07:09 | 11:27 | 12:00 | 13:53 | 15:44 | 17:32 |
| 12 | Якш | 05:02 | 05:41 | 07:11 | 11:27 | 12:00 | 13:51 | 15:42 | 17:30 |
| 13 | Дүш | 05:03 | 05:43 | 07:13 | 11:27 | 12:00 | 13:49 | 15:41 | 17:29 |
| 14 | Сиш | 05:05 | 05:45 | 07:15 | 11:27 | 12:00 | 13:48 | 15:39 | 17:27 |
| 15 | Чәрш | 05:07 | 05:47 | 07:17 | 11:28 | 12:00 | 13:46 | 15:37 | 17:26 |
| 16 | Пәнҗ | 05:08 | 05:49 | 07:19 | 11:28 | 12:00 | 13:45 | 15:35 | 17:25 |
| 17 | Җом | 05:10 | 05:51 | 07:21 | 11:28 | 12:00 | 13:43 | 15:34 | 17:23 |
| 18 | Шим | 05:12 | 05:53 | 07:23 | 11:28 | 12:00 | 13:42 | 15:32 | 17:22 |
| 19 | Якш | 05:13 | 05:55 | 07:25 | 11:28 | 12:00 | 13:40 | 15:31 | 17:21 |
| 20 | Дүш | 05:15 | 05:57 | 07:27 | 11:29 | 12:00 | 13:39 | 15:29 | 17:20 |
| 21 | Сиш | 05:16 | 05:59 | 07:29 | 11:29 | 12:00 | 13:38 | 15:28 | 17:19 |
| 22 | Чәрш | 05:18 | 06:01 | 07:31 | 11:29 | 12:00 | 13:37 | 15:26 | 17:18 |
| 23 | Пәнҗ | 05:19 | 06:03 | 07:33 | 11:29 | 12:00 | 13:35 | 15:25 | 17:17 |
| 24 | Җом | 05:21 | 06:05 | 07:35 | 11:30 | 12:00 | 13:34 | 15:24 | 17:16 |
| 25 | Шим | 05:22 | 06:07 | 07:37 | 11:30 | 12:00 | 13:33 | 15:22 | 17:15 |
| 26 | Якш | 05:24 | 06:09 | 07:39 | 11:30 | 12:00 | 13:32 | 15:21 | 17:14 |
| 27 | Дүш | 05:25 | 06:11 | 07:41 | 11:30 | 12:00 | 13:31 | 15:20 | 17:13 |
| 28 | Сиш | 05:27 | 06:12 | 07:42 | 11:31 | 12:00 | 13:30 | 15:19 | 17:13 |
| 29 | Чәрш | 05:28 | 06:14 | 07:44 | 11:31 | 12:00 | 13:29 | 15:18 | 17:12 |
| 30 | Пәнҗ | 05:29 | 06:16 | 07:46 | 11:31 | 12:00 | 13:28 | 15:17 | 17:11 |